**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 1 ноябрендәге 3803 номерлы карары**

**2026 елга Казан шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләрен финанслау нормативларын раслау турында**

2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы федераль законның 99 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законның 16 статьясындагы 13 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 8 августындагы 566 номерлы «Татарстан Республикасының гомуми белем бирү учреждениеләрен норматив буенча финанслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Түбәндәгеләрне расларга һәм 2026 елда гамәлгә кертергә:

1.1. 2026 елга Казан шәһәренең гомуми белем бирә торган барлык төр мәктәп-интернатларында тәрбияләнүчеләрне карап тотуга финанс чыгымнары нормативларын (1 номерлы кушымта);

1.2. Казан шәһәренең гомуми белем бирә торган барлык төр мәктәп-интернатларында балаларны карап тоту өчен ата-аналар түләвен формалаштыру һәм алу тәртибен (2 номерлы кушымта);

1.3. Казан шәһәренең гомуми белем бирә торган барлык төр мәктәп-интернатларында балаларны карап тоту өчен ата-аналар түләве күләмен (3 номерлы кушымта);

1.4. 2026 елга Казан шәһәренең гомуми белем бирә торган барлык төр мәктәп-интернатларында укучыларны тукландыру бәясен (4 номерлы кушымта).

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә (И.А.Ризванов):

2.1. 2025 елның 30 сентябрендәге 57-ТРЗ номерлы «2026 елга, 2027 һәм 2028 елларның план чорына Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында»гы Татарстан Республикасы законы белән расланган финанс чыгымнары нормативын, тәрбияләнүчеләрне карап тоту нормативын, милекне карап тоту нормативын, гомуми белем бирә торган барлык төр мәктәп-интернатларда балаларны карап тоту нормативын, шулай ук учреждениеләрнең хезмәт күрсәтү сыйфаты стандартлары нигезендә өзлексез эшләвен тәэмин итү максатыннан ел саен

кабул ителә торган чыгым йөкләмәләрен башкаруга чыгымнарның нормадан тыш күләмен исәпкә алып, Казан шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләре тарафыннан муниципаль биремнәрнең үтәлешен финанс ягыннан тәэмин итү күләмен билгеләргә;

2.2. 2026 ел дәвамында бюджет акчаларының үзәкләштерелгән нормативтан тыш күләмен учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү, коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә тарифлар арту белән бәйле чыгымнарны каплау һәм субсидия күләменә кермәгән башка чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен учреждениеләргә юнәлдерергә;

2.3. муниципаль йөкләмәне үтәүне финанс ягыннан тәэмин итүгә бюджет акчалары хисабына субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турындагы килешүләр нигезендә ведомство карамагындагы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренә субсидияләр күчерүне гамәлгә ашырырга;

2.4. укучылар контингенты (сыйныфлар саны) һәм (яки) биләгән мәйданнар үзгәрү өлешендә гомуми белем бирү учреждениеләренә 2026 елда муниципаль йөкләмә үзгәргән очракта, Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә 2026 елга Казан шәһәренең җыелма бюджет исемлеге чикләрендә чыгымнарны яңадан бүлү турында нигезләнгән тәкъдимнәрне тапшыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.И.Абзаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 1 ноябрендәге
3803 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**2026 елга Казан шәһәренең гомуми белем бирә торган барлык төр мәктәп-интернатларында тәрбияләнүчеләрне карап тотуга финанс чыгымнары нормативлары**

| **Гомуми белем бирү учреждениесенең тибы һәм төре** | **Бер тәрбияләнүчене карап тотуга финанс чыгымнары нормативы, бер елга сумнарда** |
|---|---|
| Гомуми белем бирә торган мәктәп-интернат | 205458 |

______________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 1 ноябрендәге
3803 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең гомуми белем бирә торган барлык төр мәктәп-интернатларында балаларны карап тоту өчен ата-аналар түләвен формалаштыру һәм алу тәртибе**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Казан шәһәренең гомуми белем бирә торган барлык төр мәктәп-интернатларында балаларны карап тоту өчен ата-аналар түләвен формалаштыруның һәм алуның әлеге тәртибе Казан шәһәренең гомуми белем бирә торган барлык төр мәктәп-интернатларында (алга таба – интернатлар) балаларны карап тоту өчен ата-аналар түләвен формалаштыру, билгеләү, үзгәртү һәм алу механизмын билгели.

1.2. Гамәлдәге законнар нигезендә балаларны интернатларда карап тоту өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) ата-аналар түләве алына.

1.3. Интернатларда балаларны карап тоту өчен ата-аналар түләвен исәпләү һәм алу тәртибе Казан шәһәре Башкарма комитеты карары белән раслана.

1.4. Интернатларда тәрбияләнүчеләрне карап тоту өчен ата-аналар түләвен билгеләгәндә исәпкә алына торган чыгымнар күләме интернатларда тәрбияләнүчеләрне карап тотуга финанс чыгымнары нормативына кертелә торган чыгымнар күләменә туры килә. Әлеге норматив ел саен Казан шәһәре Башкарма комитеты карары белән билгеләнә.

1.5. Әлеге тәртип түбәндәге төр интернатларга карата гамәлдә: башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта (тулы) гомуми белем бирә торган, шул исәптән аерым фәннәр тирәнтен өйрәтелә торган гомуми белем бирү мәктәп-интернатлары, гимназия-интернатлар, лицей-интернатлар.

## II. Интернатларда балаларны карап тоту өчен ата-аналар түләве күләмен исәпләү тәртибе

2.1. Интернатларда балаларны карап тоту өчен ата-аналар түләве бер айда бер тәрбияләнүчене карап тотуга финанс чыгымнары нормативының 25 процентыннан артмаган күләмдә билгеләнә.

2.2. Медицина бәяләмәсенә нигезләнеп, сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларны, ата-аналарның икесе дә беренче яки икенче төркем инвалид булган гаиләдәге балаларны, ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган (опекада, попечительлектә булган) балаларны, гамәлдәге федераль законнарда билгеләнгән башка очракларда балаларны интернатларда карап тоту өчен ата-аналар түләве алынмый.

Шулай ук интернатларда түбәндәге балаларны карап тотуга ата-аналар түләве алынмый:

1) Украина гражданнарының, Донецк Халык Республикасы гражданнарының, Луганск Халык Республикасы гражданнарының, Херсон һәм Запорожье өлкәләре гражданнарының һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Херсон һәм Запорожье өлкәләре территорияләрендә даими яшәгән гражданлыгы булмаган, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Херсон һәм Запорожье өлкәләре территорияләрен калдырып китәргә мәҗбүр булган һәм Россия Федерациясе территориясенә ашыгыч тәртиптә күпләп килгән затларның (Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны бирү турында таныклык күрсәткән көннән Россия Федерациясе гражданлыгы алган көнгә кадәр) балаларын;

2) түбәндәге гражданнарның гаилә әгъзалары балаларын:

- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган һәм махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар;

- Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләрендә хезмәт итүче, махсус хәрби операция алып барыла торган зонага командировкага җибәрелгән хәрби хезмәткәрләр һәм затлар;

- Татарстан Республикасында төзелгән «Алга», «Тимер» һәм «Батыр» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар;

- махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларын ирекле үтәүче гражданнар;

- Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгыннан, Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән хезмәткәрләр;

- махсус хәрби операциядә катнашкан хәрби хәрәкәтләр ветераннары;

- махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак (вафат) булган гражданнар (үлү турында таныклык күрсәткән көннән).

Шулай ук, язылышу турында таныклык нигезендә, махсус хәрби операциядә катнашучы Россия Федерациясе гражданнары гаиләләрендә тәрбияләнүче, ирнең (хатынның) беренче (башка) никахтан туган балаларын интернатларда карап тоту өчен ата-аналар түләве алынмый.

Әгәр ата-аналар түләвеннән азат итү өчен нигезләр гамәлдән чыкса, ата-аналар (законлы вәкилләр) әлеге нигезләр гамәлдән чыккан көннән алып өч эш көне эчендә белем бирү учреждениесенә бу хакта хәбәр итәргә тиеш.

2.3. Ата-аналар түләве интернатларда тәрбияләнүчеләрне карап тотуны тәэмин итү өчен булган даими зурлыктан һәм тәрбияләнүчеләрне туклану белән тәэмин итү өчен булган үзгәреп тора торган зурлыктан гыйбарәт.

2.4. Интернатларда ата-аналар түләве каникул чорында һәм авырган вакытта, тәрбияләнүче интернатта булмаган көннәр саныннан чыгып, тәрбияләнүчеләрне туклану белән тәэмин итүгә чыгымнар зурлыгына киметелергә тиеш. Бала башка сәбәпләр буенча интернатта булмаган очракта, интернатларда балаларны карап тоту өчен ата-аналар түләве үзгәрми.

2.5. Тәрбияләнүчене интернаттан башка гомуми белем бирү учреждениесенә күчергәндә, интернатта баланы карап тоту өчен ата-аналар түләве, тәрбияләнүчене күчергәннән соң, агымдагы айның калган көннәре өчен кире кайтарылырга тиеш.

2.6. Интернатларда балаларны карап тоту өчен ата-аналар түләве хисабына каплана торган азык-төлек продуктлары бәясе интернатта балаларны карап тоту өчен ата-аналар түләвеннән бүлеп алынырга тиеш.

2.7. Ата-аналар түләве, тәрбияләнүчеләрне туклану белән тәэмин итү чыгымнарын да кертеп, тәрбияләнүчеләрне карап тотуга тотыла.

## III. Интернатларда балаларны карап тоту өчен ата-аналар түләвен алу тәртибе

3.1. Балаларны интернатта карап тоту өчен ата-аналар түләве, агымдагы айның 10 нчы көненнән дә соңга калмыйч, ай саен түләнә.

3.2. Балаларны интернатта карап тоту өчен ата-аналар түләве билгеләнгән вакыттан соң ике атна дәвамында түләнмәгән очракта, күрсәтелгән сумма гамәлдәге законнарда билгеләнә торган тәртиптә түләттерелә.

3.3. Интернатта тәрбияләнүчеләрне карап тоту өчен ата-аналар түләвенең артык түләнгән өлеше, интернат җитәкчесенә аны түләгән көннән алып бер ел узганчы гариза бирелгән очракта, кире кайтарыла.

3.4. Интернатта балаларны карап тоту өчен ата-аналар түләвенең артык кертелгән өлеше интернат җитәкчесенә гариза биргән көннән соң ике атна эчендә кире кайтарыла.

___________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 1 ноябрендәге
3803 номерлы карарына
3 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең гомуми белем бирә торган барлык төр интернат-мәктәпләрендә балаларны карап тоту өчен ата-аналар түләве күләме**

| Тәрбияләнүчеләр категориясе | Ата-аналар түләвенең тәрбияләнүчеләрне карап тотуга финанс чыгымнары нормативыннан процентларда билгеләнгән күләме, % | Бер тәрбияләнүчене карап тоту өчен ата-аналар түләве күләме, бер айга сумнарда | |
|---|---|---|---|
| | | бар-лыгы | шул исәптән азык-төлек продукт-лары бәясе |
| **Гомуми белем бирә торган мәктәп-интернат, лицей-интернат, гимназия-интернат (кадет мәктәп-интернатыннан тыш)** | | | |
| Мәктәп-интернатларда яшәүче һәм ризык, кием-салым (йомшак инвентарь) алучы тәрбияләнүчеләр | 23 | 3945 | 1341 |
| Мәктәп-интернатларда яшәмәүче һәм тукланучы тәрбияләнүчеләр | 23 | 3505 | 901 |

______________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 1 ноябрендәге
3803 номерлы карарына
4 номерлы кушымта

**2026 елга Казан шәһәренең гомуми белем бирә торган барлык төр мәктәп-интернатларында укучыларны тукландыру бәясе**

| Тәрбияләнүчеләр категориясе | Бер көнгә туклану бәясе, сумнарда |
|---|---|
| Мәктәп-интернатларда яшәүче һәм тукланучы тәрбияләнүчеләр | 315,66 |
| Мәктәп-интернатларда яшәмәүче һәм тукланучы тәрбияләнүчеләр | 189,40 |

______________